# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2025 ел № 14

2026 елда Татарстан
Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Турай авыл
җирлегенең Татар Әхтиялы
авылында гражданнарның үзара
салым акчаларын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы гражданнар җыены карар кылды:

1. “2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә I төркем инвалидларны һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә.

2. Үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

2.1. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Татар Әхтиялы авылында чишмә өчен торба сузу, өй һәм эскәмияләр урнаштыру);

2.2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Әхтиялы торак пунктының Ключевая һәм Үзәк урамнары буенча юл өслегендә чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу; Татар Әхтиялы торак пунктында вак таш салганнан соң юл өслеген тигезләү ( эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2.3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

2.4. Урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау

(яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

2.5. Үзара салым акчаларының узган еллардагы калдыкларын юлларны кардан чистартуга тотарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4.. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге Башлыгы А.Т. Нуриев